# Мәктәп хәбәрчесе

№8 (№29) октябрь 2021 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите



Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


*/ Мөхәррир сүзе /*

## 5 нче октябрь – укытучылар көне

Бәйрәмегез белән, мөгаллимнәр! Гыйлемгә, рухи, мәдәни кыйммәтләргә ия булган затлар! Сез язмышыгызны кешеләргә мәгърифәт өләшу дигән изге хезмәт белән бәйләгәнсез. Сез – һәр баланы шәхес итеп тәрбияләүче, ил һәм милләт гаме белән янучы иң кирәкле, җаваплы һөнәр иясе. Сезнең ярдәм белән балалар белем серләрен төшенә, тәҗрибә туплый, олимпиадаларда, төрле конкурста катнашып көчен сыный, көрәшергә өйрәнә. Сезнең ярдәм белән сәхнәгә менеп сәнгать үрләрен яулый. Димәк, хөрмәтле укытучылар, баланың киләчәге генә түгел, илебез язмышы да Сезнең кулларда. Сез һәрвакыт укучы өчен борчыласыз, аның белән "бергә" имтихан тапшырасыз, дәресен әзерләми килгәндә дә яратып кына ачуланасыз, укучыңа беркайчан да үпкәләмисез. Киң күңеллелек, олы сабырлык, шәфкатьлелек үрнәге булган, үсеп килүче буынга әхлакый кыйммәтләрне тәрбияләгән өчен дә, сәләтләрен үстергән, талантларны барлаган өчен дә киләчәктә хөрмәт сүзләре генә ишетүегезне телибез.

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***

## 1 нче октябрь – Өлкәннәр көне

Илебез буенча 1 нче октябрьдә Өлкәннәр көне билгеләп үтелә. Төрле җирләрдә хөрмәтле картларыбызны котлаулар, бүләкләүләр белән искә алабыз. Безнең мәктәп коллективы да, үз чиратында, пенсионер укытучыларыбызны, хезмәттәшләрне бәйрәмнәре белән котлады. Заман авырлыкларына бирешмичә илебез уңышы өчен көчегезне кызганмагансыз. Бу дөньяда куйган хезмәтләрегез, кылган изгелекләрегез өчен рәхмәт сезгә! Без, яшьләр, сезнең киңәшләрегездән тайпылмабыз, үрнәк булырга тырышырбыз! Саулык-сәламәтлектә, дөньяга ямь биреп яшәгез, урыннарыгыз өйнең түрендә булсын! Бәйрәмегез белән!

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***

## 20-нче октябрь – пешекчеләр көне!

Пешекче һөнәре – зур osталык, түземлек, көч таләп итә торган эш. Бу эштә очраклы кешеләр була алмый. Бигрәк тә балалар бакчасында, мәктәптә, чөнки сабыйларны тәмле ашлар белән кызыктыру – үзе бер сәнгать.



Безнең мәктәп ашханәсендә үз эшенең осталары хезмәт куя. Илсөяр апа Сабитова, Айгөл апа Йосыпова көн саен балаларны тәмледән-тәмле ашлар белән сыйлый. Алар теләсә кайсы аш әзерләгәндә, беренче чиратта, балаларны яратып әзерли. Шуңа күрә аларның боткалары, ашлары һәм компотлары телеңне йотарлык була. Алар бу эшне төбеннән аңлап, төшенеп, дөрес итеп башкаралар. Пешекчеләрнең беренче ярдәмчеләре – Рәмзия апа, ул – ашханә җыештыручысы. Чисталык, пөхтәлек, төгәллек өчен җавап бирә. Ашханә хезмәткәрләре бердәм, тату, бер сүздә булып эшлиләр. Алар өчен иң зур бүләк – балаларның буш тәлинкәләре, канәгать эти-әниләрнең рәхмәт сүзләре.

Пешекчеләр көне уңаеннан аларны һөнәри бәйрәмнәре белән котлап иң матур теләкләрне җиткерәбез.

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***




### *Мөгаллимнәр*

Нигә кирәк икән мөгаллимнәр?
Ни өчен соң алар бик мөһим?
Кыргыйлыкка төшәр иде халык
Белем алу булмаса мөмкин.

Ни өчен соң кирәк мөгаллимнәр?
Эшләре соң нигә бик мөһим?
Ходайдан җан, әткәй-әнкәйдән тән
Җанны тәрбияли мөгаллим.

Мөгаллимлек һөнәр генә түгел
Мөгаллимлек җанның халәте.
Укучысын, эшен уйлап үтә,
Тормышының һәрбер сәгате.

Мөгаллим ул киң күңелле кеше
Җан җылысын бирә балага,
Һәрбересе йөрәгендә кала
Китсәләр дә читкә, калага.

Ходай бирә җанны ак кәгазьдәй
Нәрсә язылаcын ул белә!
Шушы битне тутырып язар өчен
Мөгаллимгә илһам, көч бирә.

***Рафик Исмәгыйлев,***
***пенсионер укытучы***

## *Хуш, Җәмил абый...*



Авылыбыз җәмәгатьчелеге зур югалтуга дучар булды. 2 нче октябрь көнне күренекле авылдышыбыз Җәмил абый Сафиуллин вафат булды.

Җәмил абый 1953 нче елның 3 нче сентябрендә Салихҗан абый белән Саимә апа гаиләсендә дөньяга килә. Авылдагы сигезъеллык мәктәпне һәм Иске Әдәм урта мәктәбен тәмамлый. Шуннан соң укуын Казан химия-технология институтында укый. Өстәмә рәвештә юридик белем дә ала. Ә ул елларда яшьләр арасында югары белем алучылар бик сирәк була.

Укуын тәмамлагач, Җәмил абый Чаллы шәһәрендә урнашып, гомере буе шунда яшәде. 1980 нче еллар ахырыннан алып Чаллыдагы милли хәрәкәтнең актив әгъзаларыннан булды. 1990 нчы елда Татарстан Югары Советына депутат итеп сайлана. Парламентның хокук комиссиясендә эшли. Татарстанның суверенлыгы турындагы Декларацияне, Республиканың Конституциясен эшләүдә катнаша. 1995 нче елда, депутатлык вазифасын калдыргач, юрист буларак эшләвен дәвам итә. Җәмәгате, күренекле язучы Фәүзия апа Бәйрәмованың кырыкка якын китабын чыгара. 5 ел дәвамында "Тарихи-мәдәни мирас" газетасын нәшер итә. 2008 нче елда әтисе Салихҗан абыйның “Мәңге онытылмас еллар хатирәсе” дигән истәлекләр китабын чыгарган иде. Җәмил абый белән Фәүзия апа безнең мәктәпнең яңа бинасын төзү эшендә башлап йөрүчеләрдән булдылар. Берничә тапкыр мәктәпкә очрашуларга кайттылар.

Шәхсән үземнең исемнән һәм мәктәп коллективы исеменнән Җәмил абыйның якыннарының тирән кайгысын уртаклашам. Урыннарың җәннәттә булсын. Кылган игелекләренең әҗер-саваплары рухыңа ирешеп торсын.

***Рафик Насыйров, мәктәп директоры***

---

**/ Рәсми хәбәрләр /**

## *Беренче чирек төгәлләнде*

25 сентябрьдән 23 октябрьгә кадәр мәктәпләрдә Бөтенроссия олимпиадасының мәктәп турлары узды. Безнең укучылар барлыгы 13 олимпиадада катнашты. Аларның нәтиҗәләре буенча, муниципаль турга 8 фән буенча (математика, рус теле, рус әдәбияты, татар теле, татар әдәбияты, география, химия, биология) 14 укучы тәкъдим ителде. Аларга уңышлар телибез.

30 нчы октябрьдә 2021-2022 нче уку елының I чиреге тәмамланды. 51 укучының 37 сенә чирек билгеләре чыгарылды. Чирекне IV сыйныфтан Закирова Ләйсән һәм V сыйныфтан Гафиятуллин Фаил гел “5” ле билгеләренә тәмамлады. Мәктәп буенча белем сыйфаты 50% тәшкил итте.

***Илдар Хәбибуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***

---



**/ Мәктәп тормышы /**

## *Мәктәптә – үзидарә көне*

5 октябрь көнне ил күләмендә укытучыларның һөнәри бәйрәме билгеләп үтелә. Безнең мәктәптә бу бәйрәм үзидарә көне буларак уздырыла. Бу көнне 10-11 сыйныфлар үзләренә укытучы вазифаларын алып, балаларны укыттылар. Алар арасыннан Насырова Сара инглиз теле һәм 3 нче сыйныф укытучысы, Сафиуллин Фазыл – математика укытучысы, Мөхәммәтова Рузилә – тарих укытучысы, Нурматов Халит – 1 нче сыйныф укытучысы, Камалов Илдус – физкультура һәм 2 нче сыйныф укытучысы, Нукина Виктория – рус теле һәм әдәбияты, Сафиуллина Зөлфирә – 4 нче сыйныф укытучысы, ә мин – Туктамышева Әминә – татар теле һәм әдәбияты белән рус теле укытучысы булдык.

Үзебезне мөгаллимнәр урынына куеп, укытучы һөнәренең нинди авыр булганлыгын аңладык. Укытучы хезмәте – һөнәр генә түгел, ә күңел халәте дә булырга тиеш икән. Укытучы исеменә лаек булыр өчен үзеңдә кешедә булырга мөмкин барлык яхшы сыйфатларны гына тупларга кирәклегенә инандык.

Яшәешне алга этәрүче, нәни сабыйлардан зур шәхес ясаучы, тәрбияләүче, тормыш юлларының дөресен сайларга өйрәтүче кеше – Укытучы ул! Рәхмәт, Сезгә, абый-апалар!

***Әминә Туктамышева, IX сыйныф укучысы***

## Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай диләр...

Мәктәп елларында шушы юлларны укыганда һәрвакыт Тукайның балачагы узган авыл – Кырлайны күрәсем килә иде. Менә, ниһаять, еллар үтү белән, шушы хыялым чынга ашты. Октябрьның матур көнендә без, мәктәп хезмәткәрләре, Арчага юл тоттык. Табигатьтәге көзге күренешләргә, төрледән-төрле төсләргә соклана-соклана Кырлайга килеп җиткәнебезне сизми дә калдык.



Сәяхәтебезне Габдулла Тукайның музей комплексыннан башладык. Музейга барасы юл тирәләренә бөек шагыйребезнең әкият геройлары – Кисекбаш, Шүрәле, Кәҗә белән Сарык, Су анасы сыннары куелган. Юл буйлап барганда әйтерсең лә әкиятле балачакка кайтасың. Ә музей алдында Бакый Урманче иҗат иткән Тукай һәйкәле кунакларны сәламләгән төсле каршы ала.

Бинага керү белән безне күркәм экскурсовод каршы алды. Чын Арча ягы сөйләме, ягымлы тавышы белән ул безгә Тукайның тормыш юлын сөйләп бирде. Шагыйрь белән, аның туганнары, якыннары белән бәйле булган кызыклы истәлекләр, мөһим ядкәрләр белән таныштырды. Бинаның икенче катында Тукайның иҗаты чагылган картиналар, композицияләр белән карадык.

Музей белән танышкан соң гаҗәп матур Ия елгасы буена төштек. Бәлки әкияттәге Су анасы образы шагыйрьнең шушы инешкә бәйле истәлекләреннән тугандыр. Елганың ярларына агачтан ясалган Шүрәле сыннары урнаштырылган. Бу урыннарда үзеңне чыннан да Тукай әкиятләрендәгедәй хис итәсең.

Музей комплексыннан Кырлай авылының тагын бер горурлыгы – Сәгъди абзый йортына юл тоттык. Җыйнак кына, биш тәрәзәле йорт, сиртмәле кое, баз, келәт, салам түбәле абзар-кура безгә моннан 100-120 ел элекке авыл тормышын күз алдына китерә. Өй эчендәге күренеш, җиһазлар, кием-салымнар, савыт-сабалар – барысы да шул заман мохитын саклап калган. Әйтерсең лә Тукай каядыр чыгып киткән дә менә-менә кайтыр төсле. Йорт белән танышып бетергәннән соң, бакчага чыктык. Биредәге нарат агачын 1893 елда Сәгъди абзый белән бәләкәй Апуш утыртканнар икән. Сәгъди абзый йорты белән танышканнан соң, экскурсовод безне күршедә генә булган байлар йортына чакырды. Өй ике катлы бик матур итеп эшләнгән. Монда без шул чорга караган бик күп эш кораллары, йорт җиһазлары белән таныштык.

Кырлай кафесында төшке ашны ашагач, Арчага, педагогия көллиятендә урнашкан Әлифба музеена юнәлдек. Безне монда музей җитәкчесе Дамир абый Таҗиев каршы алды. Иң элек ул безне көллият тарихы һәм шул уку йортын тәмамлаган күренекле шәхесләр белән таныштырды. Соңрак дөньядагы бердәнбер булган “Әлифба” музеена кердек. Музейда әлеге вакытта җитмештән артык телдә чыгарылган Әлифбалар тупланган. Икенче зал татар халкында кулланылган графикалар һәм татар әлифбасы тарихына багышлана.

Әлифбага музей ни өчен нәкъ менә Арчада ачылган соң? Бөтен татар дөньясы укый торган Әлифбаның авторлары ирле-хатынлы Сәләй Гатат улы Вәгыйзов һәм Рәмзия Гыйләҗ кызы Вәлитова Арча педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары булган дип аңлатты безгә Дамир абый. Нәкъ менә шушы гаилә безнең әти-әниләребез һәм үзебез укыган әлифбаның авторлары. Дамир абый безгә аларның бик гыйбрәтле һәм дә фаҗигале тормышларын сөйләп узды. Өченче зал шушы авторларның үзләренә багышланган. Биредә шул әлифбаны төзегәндәге кульъязмалар, гаилә үз кулы белән бүләк итеп калдырылган ядкәрләр саклана.

Тел белән әйтеп бетерә алмаслык хис-кичерешләр белән, рухи азык алып, сөекле шагыйребез турында булган белемнәребезне тагын да тулыландырып, әлифбабыз тарихы белән танышып кайтыр юлга кузгалдык.

Укытучылар көне уңаеннан, шушындый күңелле һәм файдалы сәяхәт оештырган өчен, мәктәбебез директоры Насыров Рафик Гомәр улына барлык мәктәп хезмәткәрләре исеменнән зур рәхмәтебезне белдерәбез.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

---

## Көзге экскурсия

14 нче октябрь – аяз күкле, һавадан көзге хуш исләр аңкып торган көн иде. Шул көнне без, мәктәп белән, экскурсиягә барырга дип җыелдык. Бу юлы без Югары кырдагы мәктәп посадкасы янындагы тирән чокырлы урынны сайладык. Бу чокырлар тирәсенә әле безнең әби-бабалар вакытында ук утыртылган булган. Хәзерге вакытта, кызганычка каршы, ул посадка юк дәрәҗәсендә. 2010 нчы елгы корылык андагы агачларның күбесен бетергән. Янәшәдәге 9 гектарлы тау битендә 2002 нче елда безнең мәктәп укучылары утырткан куаклар сакланып калган. Хәзер алар биек булып үсеп, тау битен яшелләндереп торалар.

Сәяхәт урынына килеп урнашкач, түбәнлектә җәелеп урнашкан авылыбызны күзәттек. Мәктәп посадкасының инде урман булып җитешкән чыршы-каеннары арасында йөрдек. Учак ягырга коры ботаклар җыйдык. Шуннан соң егетләр футбол, ә кечерәкләр таудан тәгәрәшеп куыш уйнадылар. *(дәвамы 4 нче биттә)*

Тиздән укытучы апа-абыйлар казаннарда тәмле балык шулпасы пешереп, компот кайнатып, безне табынга чакырдылар. Төшке ашны ашаганнан соң, кайтыр юлга кузгалыр алдыннан, Рафик абый безне тирән ерым төбе буйлап тау башына алып менде. Минем өчен экскурсиянең иң кызык өлеше ул менә шул тауга менү булды. Ерымның тирән ярларыннан җирнең төрле катламнарын күрә алдык. Мин үземне ниндидер тауларда сәяхәт итүче альпинист кебек хис иттем. Бу экскурсия барыбызда да күңелле истәлекләр калдырды.

*Зөлфирә Сафиуллина, X сыйныф укучысы*



## Көзге уңыш бәйрәмнәре

***/ Безнең бәйрәмнәр /***




Ел фасыллары алмашынган саен табигать тә яңа киемнәрен кия. Менә хәзер үзенең алтын төсләре белән дөньяны бизәп, көз дә килеп җитте. Бу ел фасылы, башкаларыннан үзенчәлекле матурлыгы һәм моңсулыгы белән аерылып тора. Шуңа ул үзенең моңсулыгын табигатькә өсти.

Бакчаларда инде күптән уңыш җыелып алынды. Ә уңыш җыелгач, бәйрәмен үткәрергә дә була. Елдагы гадәт буенча, безнең мәктәптә дә, көзге уңыш бәйрәмнәре булып узды. Бәйрәмне бакча төркеме башлап җибәрде. Алар 21 октябрь көнне җырлы-уенлы тамаша күрсәттеләр һәм “Йомры икмәк” әкиятен куйдылар.

Башлангыч сыйныф укучыларының бәйрәме 22 нчы октябрь көнне ике төркем арасындагы ярыш формасында үтте. Алар **“Яшелчәләр”** һәм **“Җиләк-җимешләр”** командаларына бүленеп көч сынаштылар. Ярыш таныштырудан башланды. Аннан соң бию, табышмакларның җавапларын табу, орлыкларның исемен язу, күзне бәйләп бәрәңге җыю һәм башка күңелле бәйгеләре булды. Соңыннан балаларның ясап килгән рәсемнәренә һәм эшләнмәләренә бәя бирелде. Алардан залда бик матур күргәзмә куелган иде. Ахырдан укучылар бәйрәм карарга килгән әти-әниләре белән көзге күчтәнәчләрдән авыз итеп, тәмләп чәй эчтеләр.



Өлкән сыйныфларның бәйрәме 30 нчы октябрь көнне КВН формасында үтте. **“Миләшкәй”** һәм **“Киек казлар”** командалары ярышты. Укучылар беренче булып үзләренең төркемнәре белән таныштырды. Аннан соң плакат һәм композиция яклау бәйгеләре узды. Шулай ук җыр, бию, реклама, пантомима, скетч, шигырь бәйгеләре дә бар иде. Ахырдан жюри әгъзалары чыгышларны бәяләп, “Киек казлар” командасының җиңүен игълан итте. КВН оешкан төстә үтте. Укучыларның чыгышлары тиешле сәнгати югарылыкта куелды. Бәйрәмне карарга килгән тамашачылар бик канәгать калып, күтәренке кәеф белән таралдылар.

*Бәйрәм репортажын Виктория Нукина әзерләде, X сыйныф укучысы*

***/ Котлыйбыз! /***



2 нче октябрьдә кече тәрбияче Хәбибрахманова Рузалия һәм тормыш иптәше Нурисламның кызлары **Амалия** дөньяга килде. Мәктәп коллективы исеменнән Амалиянең әти-әнисен һәм күпсанлы апа-абыйларын олы шатлыклары белән чын күңелдән котлыйбыз. Сабыегызның тормышыгызга ямь биреп, иманлы, акыллы, сау-сәламәт булып үсүен телибез.

----------------------------------------------------------------------------------------

22 нче октябрьдә туган көнен билгеләп үтүче башлангыч сыйныфлар укытучысы **Камалова Сирин** апаны гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез. Аңа гаилә бәхете, сәламәтлек, хезмәтендә уңышлар телибез.

Октябрь балалары – I сыйныфтан **Закиров Инсаф** (11.10**)** белән **Хәбибрахманова Гайшә** (17.10), V сыйныфтан **Хәбибрахманова Хәнифә**, (05.10), VI сыйныфтан **Нургалиева Ләйлә** (09.10) , VIII сыйныф укучылары **Галимов Рияз** (25.10), **Хәбибрахманов Әхмәт** (29.10), XI сыйныфтан **Нурматов Халитны** (22.10) туган көннәре белән котлыйбыз. Барыгызга да ныклы сәламәтлек, укуларыгызда зур уңышларга ирешүегезне теләп калабыз.



## *Мәктәпкә багышланган гомер*

Гәзитебез алдагы басмаларында мәгариф өлкәсендә хезмәт итеп, хәзер лаеклы ялда булган укытучылар белән әңгәмәләребезне бастыра килдек. Бу басмада хәзер безнең мәктәпнең филиалы булып торган Иске Татар Әдәмсуы мәктәбендә озак еллар эшләгән Ислямова Галина Михайловна да бар. Аңа укучылар үз итеп, “Галя апа” дәшергә гадәтләнгән. Без дә аңа шулай якын итеп мөрәҗәгать итергә булдык.

**- Галя апа, ничә ел гомерегез мәктәп, укучылар арасында үтте?**

- Мин тумышым белән Чистай районы Керәшен Ялтаны авылыннан. 1954 нче елда Иске Әдәм авылы мәктәбенә 8 нче сыйныфка укырга килдем. Ул вакытта бу мәктәп бик зур иде. Тирә-яктагы унбишләп авыл балалары бергә килеп укый иделәр. Аларга яшәү өчен махсус интернат та бар иде. Мин укырга килгәндә апам Әдәмсуы мәктәбендә укыта иде инде.

**- Сез шул килүдән монда калдыгызмы?**

- Мин урта мәктәпне тәмамлагач, Казан Дәүләт педагогия институтын тәмамладым. Кулга диплом алгач, шушы Әдәмсуы мәктәбенә укытырга кайттым. 1963 нче ел иде. Беренче хезмәт елларымда үсемлекчелек, терлекчелек дәресләрен алып бардым. Чөнки ул елларда урта мәктәпләрдә авыл хуҗалыгы кадрлары әзерлиләр иде. Трактор дәресен укып, трактор йөртү хокукы да бирелә иде мәктәптә үк.

**- Ул чорда менә шундый киң профильле мәктәптә укыту ничек оештырыла иде?**

- Безнең мәктәпнең зур мәйданлы җир участогы да бар иде. Шунда төрле үсемлекләр үстереп, тәҗрибәчелек белән шөгыльләнә идек. Укытучылар коллективы зур, тырыш иде. Бердәм эшләү нәтиҗәседер инде, булган авырлыклар сизелмичә уза иде. Ул вакытта укытуның үз хуҗалыгында терлек асравы тыела иде. Бар вакытны без бары тик мәктәп, укучы өчен генә тотарга тиеш идек.

**- Сез, белгәнебезчә, биология, география фәннәре укыттыгыз. Бу гыйлемне укучылар ничек үзләштерә иде?**

**-** Укучыларда тырышлык, җаваплылык та җитәрлек, теләкләре булганда. Мәктәпнең матди базасы нык, тәҗрибәләр өчен шартлар әйбәт иде. Шуңадырмы ул вакыттагы кыенлыклар инде истә калмаган. Иң мөһиме – балаларны яратып эшли идем.

**- Сез бит әле бу мәктәпне җитәкләгән кеше дә.**

**-** Әйе, мин 10 ел мәктәптә директор вазифасын башкардым. Шул елларда инде тирә-як авылларда мәктәпләр урта белем бирә башлады. Шулай итеп, елдан-ел мәктәбебез кечерәя барды. Авыл укытучылары алар төрле эшкә батыр, куркусыз. Шунлыктан андый коллективны җитәкләү җиңелрәктер. Бердәм, тату, тырыш укытучылар белән эшләдем. Гомерем мәктәптә – укучылар арасында үтте. Һәр баланы үз күреп, аның өчен борчылып эшләдек. Укучыларга сынмас канатлар куйганда, олы йөрәкле булганда хөрмәт итүләрен күтәргә була.

**- Сезгә әңгәмәгез өчен бик зур рәхмәт Галя апа. Исән-сау булыгыз.**

***Әңгәмәне Рузилә Мөхәммәтова алып барды, XI сыйныф укучысы***

---




## *Матур язу серләре*

23 сентябрь көнне Аксубайда бакча балалары һәм башлангыч сыйныфлар укучылары арасында “Матур язу серләре” конкурсы булып узды. Инде менә, октябрь ахырында шуның нәтиҗәләре билгеле булды. Бу конкурс берничә ел рәттән уздырылып килә һәм безнең укучыларыбыз анда уңышлы нәтиҗәләргә ирешәләр. Быел да республикакүләм бу конкурс 3 турдан торды. Беренче биремдә текстны дөрес итеп күчереп язу, икенчесе – каллиграфия элементлары кертеп алфавит төзү һәм шуны турыдан-туры бәйгедә куллана белү. Өченче турда дөрес язу элементларын истә тотып текст күчерү, логик биремнәр, сүзләрдән җөмләләр төзү эшләрен башкарырга иде. Безнең мәктәптән бу конкурста иң югары нәтиҗәгә бакча төркеменнән **Гафиятуллина Руфинә** ирешеп, җиңүче исеменә лаек булды (52 баллдан 49) (тәрбиячесе **Гөлүсә Насыйрова**). Җиңүче исеменә тагын укучыларыннан 4 нче сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, 2 нче сыйныфтан **Хусенов Дима** белән **Нурматова Асия** лаек булдылар. 1 нче сыйныфтан **Камалов Илнур**, 4 нче сыйныфтан **Насыйрова Кәүсәр** призер дипломнары алдылар. 1 нче сыйныфтан **Сафиуллина Гөлсем** катнашучы сертификаты белән бүләкләнде (укытучылары **Сирин Камалова, Гөлшат Закирова, Рузилә Хәйруллина**).




***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***



**/Чал тарихта эзле без/**

## *Кулъязма китаплар*

Безнең татар милләте – бай мәдәни мираска ия халык. Бу ядкәрьләрнең мөһим өлешен узган гасырлардан калган кулъязма һәм басма китаплар тәшкил итә. Кызганычка каршы, 1920-1930 елларда бер-бер артлы язу алышыну һәм дингә каршы көрәш халкыбызның совет чоры буыннарын әлеге меңьеллык мирастан аерды. Шуңа да карамастан, әби-бабаларыбыз бу китапларны кадерләп сакларга тырышкан, һәм аларның шактый өлеше бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Бүгенге көндә Түбән Майна авылыннан җыелган гарәп язулы китаплар тупланмасында җиде йөзгә якын нөсхә исәпләнә. Аларның төп өлеше хәзер авылның мәчетендә саклана. Иллеләп китап мәктәп музее күргәзмәләренә куелган.

Билгеле булганча, татарларда китап басу эше XIX гасыр башыннан гына киң күләмдә җәелеп китә. Аңа кадәр китаплар кулдан күчереп язылган. Ләкин кулъязма китаплар XX гасырга кадәр кулланылышта йөргән. Аларны, гадәттә, шәкертләр язу осталыгын арттыру максатыннан күчергәннәр. Музей тупланмасында Түбән Майнадан Сәгъдетдин Әхмәтҗан улы дигән шәкертнең 1852 нче елда күчергән китабы бар. XIX гасыр уртасында бу авылда имамчылык иткән Кәмалетдин мулланың бер кардәше китап күчерүче була. Бу абый, каурый каләмне имән кайрысыннан кайнаткан карага манып, 600 китап күчергән дип сөйлиләр. Кайберләрен хәтта үзе язган булган. Ул әле өйләнмәгән дә килеш Төркиягә китеп бара һәм кире авылга кайтмый. Безгә хәтта аның исеме дә билгесез.

Кызганычка каршы, тупланмада тулысынча сакланган кулъязмалар юк. Авылдан 1973 нче елда алып киткән яхшы хәлдәге 5 татарча кулъязма китап хәзер Казан университеты китапханәсендә саклана. Аларда мәшхүр “Тәварихе Болгария”, “Җөмҗөмә солтан”, “Сәетбаттал” әсәрләре, горрәлек (календарь) һәм догалыклар урын алган. Тагын кырыктан артык кулъязма моннан 20 ел элек Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының мирасханәсенә тапшырган идек. Аларның эчтәлеге әле хәзер дә өйрәнелмәгән.

Бүгенге көндә мәчеттәге иске китаплар тупланмасында 38 кулъязма саклана. Аларның күпчелеге берничә битле фрагмент хәлендә. Тулырак сакланган кулъязмалардан иң кадерлеләре – Коръәннең һәм “Кыйссаи Йосыф” әсәренең XVIII гасыр күчермәләре.

Кулъязма китапларның шактый өлеше антологик характерда. Аларда, гадәттә, төрле жанрга караган һәм төрле телдә язылган берничә әсәр урын алган. Кайвакыт төрле елларда күчерелгән язмалар бергә тупләнә. Еллары күрсәтелмәгән очракта, кулъязмаларның язылу вакытын кәгазеннән чамаларга мөмкин. XVIII гасыр кәгазе бик тупас булса, XIX гасырның беренче чирегендә зәңгәрсу төсле кәгазь кулланылган.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

---

**/Безнең спорт/**




## *Шахматчабыз Бөтенроссия турнирында*

2-9 ноябрь көннәрендә Самара өлкәсенең Циолковский исемендәге шәһәр яны санаторий комплексында, классик шахмат төре буенча авыл җирлекләрендә яшәүче мәктәп укучылары арасында Бөтенроссия турниры үтте. 8 көн дәвам иткән турнир бик киеренке шартларда узды. Биредә Россиянең төрле төбәкләреннән – Төмән, Әстерхан, Түбән Новгород, Псков, Волгоград, Чиләбе, Самара, Пенза, Оренбург, Свердлау, Ленинград өлкәләреннән, Алтай краеннан, Татарстан, Башкортстан, Дагстан, Удмуртия, Карачай-Черкес, Марий Эл Республикаларыннан килгән 104 шахматчы көч сынашты. Шулар арасында мәктәбенең V сыйныф укучысы Гафиятуллин Фаил дә үз мөмкинлекләрен сынады. 2009-2010 елгы 56 укучы арасында Марий Эл Республикасы шахматчысы белән өченче урынны бүлешеп, коэффициент буенча IV урынга лаек булды. Фаилне шундый зур уңышы белән чын күңелдән котлыйбыз. Алда тагын да югарырак үрләр яулавын телибез!!!

---

## *Илдусның чираттагы уңышы*

14-15 нче октябрьдә Базарлы Матакта билбау көрәше буенча республикакүләм ярыш уздырылды. Бу бәйгедә X сыйныф укучысы Камалов Илдус үз авырлыгында (60 кг) II урынга ия булды.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Сара Насыйрова
Виктория Нукина
Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина